КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО СОЦИАЛЬНО-ЭКОНОМИЧЕСКОМУ МОНИТОРИНГУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ - ИКЪТИСАДЫЙ МОНИТОРИНГ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.08.2015 г. Казань № 22-ос

**Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль законының 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау турында» 2003 елның 12 маендагы № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Гражданнарның һәм оешмаларның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләренә анализ уздыруның бердәм тәртибен урнаштыру максатларында, **б о е р ы к б и р ә м**:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына (алга таба – Комитет) кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибен расларга.
2. Юридик сектор мөдирен (Р.Р. Бурцеваны) Комитетка кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру өчен җаваплы зат итеп билгеләп куярга.
3. Юридик секторның 2 нче категория белгече (Ю.Ф. Иксанов) Комитетның рәсми сайтындагы «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә әлеге боерыкны урнаштырырга тиеш.
4. Әлеге боерыкны тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары О.Ю. Семенова

Татарстан Республикасының
Социаль-икътисадый
мониторинг комитетының
2015 елның «7 » августында № 22-ос
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ уздыру тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына (алга таба – Комитет) кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә (алга таба – мөрәҗәгатьләр) анализ уздыру тәртибе гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерә торган сәбәпләрне ачу, шулай ук Комитетта мөрәҗәгатьләр белән эшләүне камилләштерү максатларында эшләнде.

1.2. Комитетка кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, тиешле чор эчендә кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, шул исәптән: язма рәвештә, Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон хәбәрләр рәвешендә, «Кайнар линия» телефоны буенча гражданнарны шәхси кабул итү барышында алынган хәбәрләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Мөрәҗәгатьләрне анализлау мәгълүмат җыю, аны өйрәнү, гомумиләштерү, бәяләү һәм нәтиҗәләр әзерләү юлы белән гамәлгә ашырыла, бу чакта кергән мөрәҗәгатьләрнең сан һәм сыйфат характеристикалары исәпкә алына, кабат мөрәҗәгать итүләр исәпкә алына, сорауларның төп тематикалары ачыклана, мөрәҗәгатьләрне карау срокларын бозу өлешендә башкару дисциплинасының торышы анализлана.

1.4. Анализ нәтиҗәләре рәис урынбасары барында карала һәм хезмәт эшчәнлеген планлаштырганда исәпкә алына, шулай ук мөрәҗәгатьләр белән эшләү нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итүче чаралар исемлеге формалаштырыла.

## 2. Эшне оештыру

2.1. Һәр яртыеллык йомгаклары буенча (хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр) Комитетка кергән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру өчен җаваплы зат кергән мөрәҗәгатьләрне анализлый һәм гомумиләштерә.

2.2. Кергән мөрәҗәгатьләргә турыдан-туры анализ «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары документларының электрон әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

2.3. Комитетка кергән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру нәтиҗәләре буенча Комитетта мөрәҗәгатьләр белән эшләү буенча аналитик белешмә рәсмиләштерелә.

2.4. Аналитик белешмәдә (хисап чорында) түбәндәгеләр булырга тиеш: язма рәвештәге, электрон документ рәвешендә кергән, бүтән адреска җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләрнең, телдән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны, гражданнарны

кабул итү урыннары, көннәре сәгатьләре турында, шәхси кабул итүдә һәм шәхси күчмә кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар турында белешмәләр, шул исәптән кабул ителгән норматив актлар (булса) турында мәгълүмат, шулай ук үткән елның шул ук чорындагы характеристикалар турында.

2.5. Мөрәҗәгатьләрне анализлау ачык мәгълүмат була, хисап чорыннан килүче айның 20 числосына кадәр Комитетның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә урнаштырыла, шулай ук Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча Татарстан Республикасы Президенты идарәсенә җибәрелә.